**Татарстан Республикасы**

**Яңа Чишмә муниципаль районының « Әдәмсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Бакташ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАРЫ**

2019 елның 22 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы « Әдәмсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының 2019 елның 9 октябрендәге 2019 елның 58-129 номерлы "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" карары нигезендә, 2019 елның 20 ноябрендә Яңа Чишмә муниципаль районының Бакташ авыл җирлегендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәләләр каралу турында җыенның беркетмәсе төзелде:

"Сез, Әдәмсә авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән, 2020 елда, 500 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучының тол хатыннары, 90 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнар азат ителә. Үзара салым түләүдән җыелган акчалар түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- Бакташ авылларында юлларны кардан чистарту

-Бакташ авылы зиратына контейнер мәйданчыгы урнаштыру (материаллар, ике контейнер сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

«РИЗА" "КАРШЫ" "ТЫЕЛУЧЫЛАР".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә барлыгы 22 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар санына 15 граждан кертелгән.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен 15 граждан тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

"Тыелучылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Бакташ авыл җирлеге Әдәмсә авылында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2.Түбәндәге мәсьлә буенча кабул ителгән карарны танырга

"Сез Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Бакташ авыл җирлеге Әдәмсә авылында биләмәсендә теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән, 2020 елда, 500 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучының тол хатыннары, 90 яшьтән өлкәнрәк булган

гражданнар азат ителә. Үзара салым түләүдән җыелган акчалар түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- Бакташ авылларында юлларны кардан чистарту

-Бакташ авылы зиратына контейнер мәйданчыгы урнаштыру (материаллар, ике контейнер сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Әдәмсә авыл җирлегенең мәгълүмати стендлары аша халыкка җиткерергә,Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Әдәмсә авыл
җирлеге башлыгы                                                    Л.С.Котова